# БЕР ТАУДА УН ЧИШМӘ

*ӘГЪЗАМ ФӘТТАХ музыкасы*
*СИБГАТ ХӘКИМ сүзләре*

Бер тауда ун чишмә,
Унысы ун төстә;
Югыйсә бер үк тау.
Югыйсә бер үк җир.
Юлы бер...

Бер тауда ун чишмә,
Тынмыйлар бер кич тә, .
Чәчәкле җәй әле,
Атлы һәм җәяүле
Юлыгыр...

Бер тауда ун чишмә,
Унысы ун төстә;
Берсе тиз болгана,
Берсе тиз моңлана.
Ком — ташта...

Бер тауда ун чишмә,
Юлларын син кисмә;
Агышы ун төрле,
Тавышы ун төрле,
Моң башка..

Бер тауда ун чишмә,
Ун яшь кыз — ун төштә,
Сөйләшеп туймыйлар.
Туй, диләр, туй, диләр,
Чибәрләр...

Бер тауда ун чишмә,
Серең не син чишмә,
Серең не чибәрләр
Дөньяга сибәрләр,
Сибәрләр...